ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законының 5$^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5$^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктның беренче абзацында “кирәкле хезмәт стажына” сүзләрен “кирәкле стажга” сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 пунктның беренче абзацында “кирәкле хезмәт стажына” сүзләрен “кирәкле стажга” сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“3. Татарстан Республикасының әлеге статьяның 1 һәм 2 пунктларында саналмаган дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән һәм картлык буенча яки тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләнүгә кирәкле стажга ия булган, пенсияләре “Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында” һәм “Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында” федераль законнар нигезендә билгеләнгән затларга социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:”;

4) 4 пунктта “кирәкле хезмәт стажына” сүзләрен “кирәкле стажга” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 11 апреле
№ 23-ТРЗ